РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 15 » 02 2018 ел** **№ 32**

2018 елга Азнакай муниципаль районында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 20 декабрендәге 1691/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2018 елның беренче яртыеллыгына һәм 2018 елның I кварталына торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, карар итәм:

1. 2018 елга Азнакай муниципаль районында гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакы тәртибе:

- ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 233 474,00 сум;
- ике кешелек гаилә өчен - 1 569 876,00 сум;
- өч кешелек гаилә өчен - 2 018 412,00 сум;
- дүрт кешелек гаилә өчен - 2 691 216,00 сум;
- биш кешелек гаилә өчен - 3 364 020,00 сум;
- алты кешелек гаилә өчен - 4 036 824,00 сум;
- җиде кешелек гаилә өчен - 4 709 628,00 сум;
- сигез кешелек гаилә өчен - 5 382 432,00 сум;
- тугыз кешелек гаилә өчен - 6 055 236,00 сум;
- ун кешелек гаилә өчен - 6 728 040,00 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме исәпләү нигезендә түбәндәгеләрне төзи: ялгыз яшәүче граждан - 11 178,04 сум;

- ике кешедән гаиләләр 7 113,30 сум;
- өч һәм аннан да күбрәк кешелек гаиләләр - 6097,11 сум.

2. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Исәпләү һәм хисаплылык бүлегенә шушы карарга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә рәсми басмада - «Маяк» газетасында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru..

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары Г.Г. Сөләйманова